# Алмаш

Балалар һәм яшүсмерләр газетасы
Кәрәкәшле төп гомуми белем бирү мәктәбе
Девиз: "Көн саен игелекле эш кыл"
№3, декабрь,2017ел.

## ***Укучыларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту.***

*Бүгенге көндә Бөтендөнья сәламәтлекне саклау оешмасының мондый билгеләмәсе бар:"Сәламәтлек- авырулар һәм физик кимчелекләр булмау гына түгел,ә бәлки тулысынча физик, рухи һәм социаль яктан имин булу ул".Сәламәт булырга теләү – кешенең табигый омтылышы. Сәламәт тормыш рәвеше күнекмәләре балачактан гаиләдә һәм мәктәптә үзләштерергә тиеш.*

*Безнең мәктәптә дә укучыларның сәламәтлеген саклау һәм ныгытуга багышланган чаралар уздырыла.Һәр көн иртәнге гимнастикадан башлана,дәресләрдә ял минутлары уздырыла.Спорт-сәламәтләндерү дәресләрендә системалы белемнәр бирелә,хәрәкәтле уеннар өйрәтелә. Дәресләр, нигездә, саф һавада үткәрелә. Уеннар ярдәмендә балаларда оешканлык ,җитезлек, игътибарлык кебек матур сыйфатлар тәрбияләнә.Уеннар балаларның физик үсешенә һәм психикасына уңай йогынты ясый.*

*Сәламәтләндерү һәр дәрестә дә дәвам итә,төрле физкультминутка-лар үткәкелә.*

*Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Ахметова Э.Ф.*



# *Əнием, алтыным,минем иң якыным.*

*25 нчы ноябрь көнне мәктәбебездә*
*әниләр көне буларак билгеләнеп үтелде.*
*Әни,әнием,әнкәй!*
*Кадерләп назлап әйтәбез,күңелебездәге бөтен рәхмәтне шушы гади сүзгә салабыз,һәрвакыт яныбызда булган, уңышларыбыз өчен шатланып, кайгыларыбызны уртаклашып яшәгән газиз әниебезгә дәшәбез.*

*Башлангыч сыйныф укучылары әниләрне кадерләп үз куллары белән аларга бүләкләр ясадылар.4 нче сыйныф укучылары әниләрен бәйрәм табыны ясап кунакка чакырдылар,мәктәптә бәйрәм ясадылар.*

*Урта сыйныф укучылары әниләргә багышлап стенд газета-лар чыгардылар,үзләренең хисләрен шигырьләр аша иң кадерле кешеләренә җиткерделәр.6 нчы сыйныф укучылары әниләрен сыйныфларында уздырылган чарага чакырдылар,күңелле ял иттеләр.*

*Садыкова Алина 7 нче сыйныф укучысы.*




*Мәктәп күләм чаралардан  фоторепортаж*







# Котлыйбыз

*Декабрь   аенда  туган көнәрен билгеләп*
*үтүче  укучыларыбыз:Степанова Виктория,Миннегалимов Вильдан,Гибаева Гөляз,Ибрагимов Динар,Ахмадуллина Алия, Ахметов Фәннур,Ахметов Айнур!*


*Сезне   чын күңелебездән туган көннәрегез белән котлыйбыз!*

*Укуыгызда зур уңышлар,ныклы сәламәтлек,күтә-ренке кәеф юлдаш  булсын сезгә.*

*Дөньядагы һәрбер яхшылыктан*
*Өлеш чыксын сезгә мул гына.*
*Без телибез сезгә ак бәхетләр,*
*Шатлыкларга илткән юл гына.*
*Бәйрәмнәрнең матур хәтирәсе*
*Күңелегездә калсын уелып.*
*Тәбриклибез сезне чын күңелебездән,*
*Барыбыз да бергә җыелып.*

*Редколлегия.*

# "Алмаш" мәзәкләре.



- Менә сиңа ун кәнфит,яртысын энеңә бир.
- Мин аңа өчне бирәм.
- Син нәрсә саный белмисеңме әллә?
- Мин беләм,ә ул –юк.

***

*Алмаз:*
*-Алсу,мин дага таптым.Син беләсеңме, моны нәрсәгә юрарга икән?*
*Сеңлесе бик кайгырып:*
*-Беләм, кайдадыр бер мескен ат яланаяк йөгереп йөри...*

***

*Лейтенант әти һәм укучы улы.*
*-Әти, хәрбиләр һәрвакыт тыныч була белә, диләр.Бу дөресме?*
*-Алай булгач, мин сиңа хәзер көндәлегемне күрсәтәм.*

*Редактор: Ахметова Э.Ф.*
*Секретарь:* Миннегулова В.С.
Садыкова А.И.
Ахметова А.Ф.

.